КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 апрель г.Казань № 258

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы; 2022 ел, 15 март, 240 нчы; 2022 ел, 22 июль, 707 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы; 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы; 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 168 нче; 2023 ел, 4 июль, 786 нчы, 2023 ел, 09 август, 961 нче, 2023 ел, 05 октябрь, 1239 нчы, 2024 ел, 04 март, 119 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль фәнни-техник программа кысаларында җитештерелгән элиталы орлыкчылыкка ярдәм итүгә һәм (яисә) орлыклар сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибе;»;

дүртенче абзацта «авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль бюджеттан финанслаша торган җирләрне химик мелиорацияләү

чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсуслаштырылган ит токымнарының мөгезле эре терлекнең (нәселле терлектән тыш) ана товар баш санын асрауга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибе;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль бюджеттан финанслана торган авыль хуҗалыгын иминләштерүгә ярдәмгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе;»;

унтугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты кысаларында мелиорация проектларын гамәлгә ашыруга чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибе;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм федераль бюджеттан финанслаша торган «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы гражданнар тарафыннан җитештерелгән бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләрен җитештерүне арттыруны стимуллаштыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;

Татарстан Республикасы бюджетыннан сөт эшкәртүгә ярдәм итү өчен федераль бюджеттан финанслана торган эшкәртелмәгән эре мөгезле терлек, кәҗә һәм сарык продукциясен азык-төлек продукциясенә субсидияләр бирү тәртибе.»;

әлеге карар белән расланган Федераль бюджеттан финанслана торган элиталы орлыкчылыкны үстерүгә юнәлдерелгән чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен, Федераль бюджеттан финанслана торган культуртехник, агроурманмелиоратив һәм гидромелиоратив чаралар уздыруга бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен, Федераль бюджеттан финанслана торган чәчүлекләрдә әче туфракны известьлау өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен, Федераль бюджеттан финанслана торган ит терлекчелеген үстерүгә чыгымнар өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә авыл хуҗалыгы иминләштерүе шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләүгә чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм эшкәртүчеләргә федераль бюджеттан финанслана торган тотылган чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, Агросәнәгать комплексында федераль бюджеттан финанслана торган инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентлар түләүгә чыгымнар өлешен

каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, Федераль бюджеттан финанслана торган «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты кысаларында чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен, Бәрәңге һәм яшелчәләр җитештерүне арттыруга федераль бюджеттан финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгәнннәр);

әлеге карарга Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм федераль бюджеттан финанслана торган «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын куллanучы гражданнар тарафыннан җитештерелгән бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләрен җитештерүне арттыруны стимуллаштыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, Федераль бюджеттан финанслана торган эре мөгезле терлек, кәҗә һәм сарык сөтен азык продукциясенә эшкәртүгә ярдәм итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен өстәргә (карарган теркәлгәннәр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин